**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 15 апрель

№ 224

г. Казань

2015 елда «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында хәбәрләрне карап тикшерү кысаларында кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләрен тәэмин итү һәм саклау мәсьәләләре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында катнашучыларның 2015 елда «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – «Халык контроле» системасы) хәбәрләрне карап тикшерү кысаларында кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләрен тәэмин итү һәм саклау мәсьәләләре буенча докладларын тыңлап һәм фикер алышып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына («Халык контроле» системасы категорияләре модераторларына һәм үтәүчеләренә) тәкъдим итәргә:

«Халык контроле» системасындагы хәбәрләргә «Заявка хәл ителде» статусын вакытында бирергә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ««Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшләве кысаларында Татарстан Республикасы гражданнары, дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнарының электрон багланышлары турында» 2012 ел, 10 август, 676 нчы карары нигезендә «Планлаштырылган» статусы белән хәбәрләрне үтәүнең контроль вакытларын күчерүне булдырмаска.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына 2016 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына авыруы сәбәпле кресло-коляскадан файдаланучы инвалидларны гаризалары буенча үз-үзенә хезмәт күрсәтүгә һәм хәрәкәтләнүгә сәләте 2 яки 3 дәрәҗәдә чикләнгән инвалидның хосусый милкендә булган торак урынны социаль ипотека программасы буенча төзелгән тигез кыйммәттәге торакка алыштыру юлы белән алыштырып күпфатирлы йортларның беренче катларында урнашкан торак урыннарга күчерү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

«Халык контроле» системасында «Поликлиникалар һәм хастаханәләр» категориясе буенча амбулатор-поликлиника учреждениеләрендә пациентларның табиб-белгечләр кабул итүне көтүнең чик вакытларын бозу белән бәйле нигезле шикаятьләр булуга китерә торган сәбәпләрне бетерү буенча чаралар күрергә;

2016 елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау учреждениеләренең үз сайтларында гарантияләнгән түләүсез медицина ярдәме күләме турында, табиб-белгечләр консультацияләр күрсәтүне көтүнең билгеләнгән нормативлары, диагностик кораллы һәм лаборатория тикшерүләре хакында мәгълүматны актуальләштерү һәм аның тулылыгы буенча эшне оештырырга.

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт хезмәт инспекциясе белән берлектә 2016 елның 1 июненә кадәр «Халык контроле» системасында «Хезмәт хакын түләмәү» хәбәрләр категориясен төзү турында тәкъдимнәр әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына тикшерү-күзәтчелек органнары белән берлектә «Халык контроле» системасында «Хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштермәү» категориясе буенча хәбәрләрне карап тикшерү кысаларында һәр аерым очракта эш бирүче эшләр башкару яки хезмәтләр күрсәтү өчен белгечләр туплауны гамәлгә ашырган барлык шартларны исәпкә алып, хезмәт шартнамәләре урынына граждан-хокук шартнамәләре төзүнең законлы булу фактын тикшерергә;

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең башкарма комитетына хәрәкәтләнү сәләтләре чикләнгән III төркем инвалидларны Казан шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларында түләүле муниципаль парковкаларда (парковка урыннарында) түләүдән азат итү турында мәсьәләне карап тикшерергә;

Татарстан Республикасының Казан ш., Чаллы ш., Түбән Кама, Лениногорск, Зеленодольск, Бөгелмә, Чистай муниципаль районнары җирле үзидарә органнарына районнарның, шәһәр округларының тиешле программаларын һәм бюджетларын төзегәндә 2012 – 2014 елларда «Халык контроле» системасына кергән хәбәрләрне исәпкә алырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков